**ГЛАВА**
**Кадряковского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кадрәк авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.10.2022 Кадрәк авылы № 3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге башлыгы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2022 елның 11 ноябрендә 10 сәг. 00 мин. гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2023 елда үзара салым акчаларын кертүгә һәм куллануга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт узучы затлардан һәм irектән мәхрүм итү урыннарында булганнардан тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллап, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану”:

1. Кадрәк авылы урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу һәм башкарылган эш өчен түләү)

2. Кадрәк авылының Ленина, Сосновая, Заречная, Молодежная урамнары очен вак таш алу һәм ремонтлау.

3. Кадрәк авылында янгын куркынычсызлыгын беренчел чаралар белән тәэмин итү (штаттан тыш янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт хакы түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

4. МТЗ-82 тракторы өчен асылмалы җиһазлар һәм запас частьләр сатып алу

5. Авыл зиратына керү капкасын сатып алу һәм урнаштыру

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кадрәк авылы, Ленина урамы, 55 йорт адресы буенча авыл мәдәният йорты территориясендә гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы А.А. Михайлов

Агрызский муниципальный район Республики Татарстан
Совет Кадряковского сельского поселения
Кадрәк авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002558
Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы